Муса Җәлил

# Парашютсыз курчак



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)-5
Җ 82

Төзүчесе һәм кереш сүз авторы *Рафаэль Мостафин*
Рәссамы *Зөфәр Хәкимов*

**Җәлил Муса**

Җ 82 Парашютсыз курчак: Балалар өчен шигырьләр, җырлар һәм поэма. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — 79 б.

Бу җыентыкта Муса Җәлилнең балаларга багышланган шигъри иҗаты чагылыш тапкан. Күп еллар үтүгә карамастан, ул үз әһәмиятен әлегәчә югалтмаган. Китап шагыйрьнең тууына 100 ел тулуга багышлана.

ISBN 5-298-01373-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

# ҮЛЕМСЕЗ ҖЫР

*Җырым белән дусны иркәләдем,*
*Җырым белән җиңдем дошманны.*

*Муса Җәлил*

Муса Җәлил... Бу исем һәр татар кешесенә, һәр мәктәп баласына яхшы таныш. Ул халык йөрәгендә Ватанга тугрылык, үлемсезлек, батырлык һәм каһарманлык символына әверелгән.

Шагыйрьнең Моабит төрмәсендә язылган шигырьләре, дистәләрчә чит ил һәм Россия милли телләренә тәрҗемә ителеп, бөтен дөньяга таралды.

* * *

Муса Мостафа улы Җәлилов (Муса Җәлил) 1906 елның 15 февралендә Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне авылда алгач, Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга керә. 1919 елны тиф авыруыннан әтисе үлә, яшь Муса ярдәмчесез кала. Шул ук елны ул туган авылына кайта.

Муса җиде-сигез яшеннән, Тукайга ияреп, шигырьләр яза башлый. 1919 елны аның «Бәхет» дип аталган иң беренче шигыре Төркестан фронты тарафыннан чыгарыла торган «Кызыл йолдыз» газетасында басылып чыга. Мусага ул вакытта нибары 13 яшь була. Шуңа күрә имзасын да «Кечкенә Җәлил» дип куялар.

1922 елның көзендә Муса Җәлил, Казанга килеп, «Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә эшли, рабфакта укый. Яңадан Оренбург якларына кайтып, ике ел комсомол эшендә эшли, яшьләр белән аралаша.

1927 елда Җәлил Мәскәү дәүләт университетының этнология (әдәбият) факультетына укырга керә. Шул ук вакытта ул Мәскәүдә татар телендә чыгарыла торган «Кечкенә иптәшләр» исемле балалар журналының җаваплы редакторы булып эшли.

Бу журнал 1924 елдан чыга башлый. Яшь Муса редакциягә үзенең шигырьләрен, хикәяләрен, скетчларын җибәреп тора, редколлегия әгъзасы булып сайлана. 1927 елның ноябрь аеннан җаваплы мөхәррир һәм шул ук вакытта бердәнбер әдәби хезмәткәр вазифасын башкара. Озакламый бу журнал «Октябрь баласы» исеме белән чыга башлый. Җәлил монда 1932 елга хәтле — журнал Мәскәүдә ябылып, аның редакциясе Казанга күчерелгәнче эшли. Мусаның балалар өчен язылган бик күп әсәрләре нәкъ шушы журналда дөнья күрә дә инде.

Утызынчы елларда М.Җәлил рус язучыларының балалар өчен язылган әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүдә актив катнаша. Мәсәлән, ул Агния Барто, Самуил Маршак, Нина Саконская әсәрләрен тәрҗемә итеп, Казанда бастырып чыгара.

Зур художник буларак, М.Җәлил балалар әдәбияты өлкәсендә дә бай иҗат мирасы калдыра. Аның нәниләр өчен язылган парчалары гаҗәеп төгәлләнгән бер формада эшләнгән. Шагыйрь балалар психологиясен тирән аңлый, аның бөтен нечкәлекләрен белеп эш итә.

Муса Җәлилнең балалар өчен язылган беренче әсәре итеп «Бишек янында» исемле җыры санала. Ул 1922 елда уналты яшьлек шагыйрь тарафыннан язылган. Муса аны үзе исән чакта бер басмага да бирмәгән, әсәр шагыйрьнең архивында гына сакланган. Беренче мәртәбә өчтомлыкта (1955) басылды.

Беренче басылган балалар шигыре итеп «Тукайны сагыну» (Балалар күңеленнән) әсәре санала. Бу шигырь 1923 елда Казанда басылган «Кызыл гөлләр» исемле күмәк җыентыкта дөнья күргән. Бу әдәби җыентык совет чорында чыккан беренче балалар китабы булып исәпләнә. Шул ук җыентыкка М. Җәлилнең «Әрсез балыкчы» исемле хикәясе дә кергән.

Югарыда әйтелгәнчә, М. Җәлилнең балалар өчен язылган шигырьләренең күбесе шагыйрь үзе җитәкләгән «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» журналларында басыла. Әйтик, аның «Лагерьда» исемле шигыре «Октябрь баласы» журналының беренче санында ук чыга. Бу журналны Җәлил үзе оештыра һәм соңгы санына хәтле җитәкли. Шул ук журналда Мусаның «Мәчегә — көлке, тычканга — үлем», «Бакчада — өмәдә!», «Шакир белән Гали» һ.б. бик күп шигырьләре чыга. Шагыйрь аларны «М» имзасы белән яки бөтенләй имзасыз бастыра (үзе баш мөхәррир булгач, тулы исемен куярга уңайсызлана, күрәсең).

Шул ук журналда шагыйрьнең уенлы җырлары, шигырьләре дә басыла. Әйтик, «Күрсәт әле» шигыре ахырында М. Җәлил шундый аңлатма биргән: «Бу җырны күмәкләп уйный-уйный җырларга була. Уртага Камали, Кәримәләрнең берәрсе кереп баса. (Кем кереп басса, шуның исемен куярга була.) Әйләнәдәгеләр, сорау биреп, җыр җырлыйлар. Түгәрәктәге кеше эш эшләп күрсәтә һәм җавап бирә. Башкалар аңа ияреләр». Шигырь журналда ноталар белән бергә бирелгән (Латыйф Хәмиди музыкасы).

Шул ук Л. Хәмиди көе белән «Октябрь баласы»нда «Куян» шигыре дә басылган. Автор шундый искәрмә ясаган: «Бу җырны уен белән бергә алып барырга була. Берәү, куян булып, чүгәләп йоклап утыра. Башкалар тотынып, әкрен генә җырлый-җырлый, аңа киләләр. Куян куркып уянганда, алар туктап торып кына җырлыйлар. Шуннан куян, сикереп качып, бер җиргә китеп яшеренә. Болар сорау бирә-бирә җырлыйлар. Куян аларга төрле җирдән төрлечә җавап бирә. Җыр беткәч, төрлесе төрле җирдән эзли башлыйлар. Тапкан кеше куян була».

Җәлилнең балалар өчен язылган шигырьләренә, җырларына атаклы композитор Җәүдәт Фәйзи дә байтак көйләр иҗат итә. («Күке», «Чишмә», «Әтәч», «Шмидт бабай», «Маэмай» һ.б.) 1940 елда бу җырлар (Муса Җәлил сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы) ноталары белән бергә «Балалар өчен беренче альбом» исемле китапта басылып чыгалар.

«Бер шигырь» исемле әсәрнең дә тарихы шактый кызыклы. 1937 елның 10 ноябрендә Муса Җәлил кызы Чулпан белән Мәскәүдә рәсемгә төшә (бу көнне Чулпанга җиде ай тула). Муса бу рәсемне туганнарына шундый язу белән бүләк итә: «Чулпан һәм этисе Муса Җәлилләр — бабай, әби һәм Газиз абыйга — Чулпаннан истәлек». (Бабай, әби — Җәлилнең хатыны Әминә ханымның әти-әнисе Котдус һәм Рабига Сәйфуллиннар; Газиз — Әминә ханымның энесе Газиз Сәйфуллин.) Бу сүзләргә өстәп, М. Җәлил кечкенә Чулпан исеменнән әлеге шигырьне дә яза.

Шигырь автор үзе исән чакта басылмый кала, беренче мәртәбә 1966 елда гына дөнья күрә.

Җәлилнең балалар өчен язылган әсәрләре төрле жанрларда, төрле буяулар кулланып иҗат ителгән. Шигырьләре балалар күңеленә бик якын, укучыны үзенә бәйләп тора, авторга карата тирән ихтирам хисләре уята. Аның бишек җырлары татар халык авыз иҗаты энҗеләренә бик якын. Алар җанлы тел белән язылган, тирән хис белән сугарылган.

Тукай традицияләрен дәвам итеп, Җәлил яшь укучыларны туган илен, хезмәтне сөяргә, Ватанга турылыклы булырга өйрәтә. Җәлил өчен балалар — тормышны алга, матур киләчәккә илтүчеләр, илгә тагы да нәфисрәк төс бирүчеләр. Алар — иҗатчылар, зурларга ярдәмчеләр, эш сөючеләр. Җәлил шигъриятендә хезмәткә дан җырлана. Хезмәтне шагыйрь кеше күңелен нурландырырлык көч итеп күрсәтә, балаларны тормышта эз калдырырлык булып үсәргә димли.

1935 елны М. Җәлил балалар өчен «Джим» поэмасын яза. Монда ул фашистик Германиянең асылын бик тәэсирле һәм нәни балалар да аңларлык итеп күрсәтә. Шагыйрь хисләре монда ташкын кебек ага. Беренче карашка поэма бик гади, әмма шул ук вакытта тирән эчтәлекле. Әсәр азатлык өчен көрәш романтикасы белән сугарылган.

Шагыйрьнең поэтик осталыгына сокланмый мөмкин түгел. Ул балаларны изгелеккә, хезмәткә, матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Татар һәм рус әдәбиятының иң яхшы традицияләрен дәвам итеп, М. Җәлил зур темалар күтәрә, һәр теманың яңача чагылышын эзли. Фикерен ул беркайчан да ялангач хәлдә бирми — ачык һәм матур калыпка салып гәүдәләндерә, яшь укучының күңелен уятырлык итеп яза. Җыентыкка кергән һәр шигырьнең үз музыкаль аһәңе бар, алар барысы да тирән һәм тәэсирле поэтик хис белән сугарылган.

1941 елда фашистик Германия белән сугыш башлангач, Җәлил үзе теләп сугышчылар сафына баса. Минзәләдә кыска вакытлы хәрби курсларны тәмамлаганнан соң, Муса Җәлил Волхов фронтына, «Отвага» газетасы редакциясенә хәрби корреспондент итеп җибәрелә. Ул анда көн саен диярлек алгы сызыкта була, кыска хәбәрләр, сугышчылар турында әдәби язмалар бастыра. Шул ук вакытта үзенең шигъри иҗатын да дәвам итә.

1942 елның июнь азагында Волхов фронтындагы каты сугышлар вакытында чолганышта калган шагыйрь, каты яраланып, һушсыз хәлдә дошман кулына эләгә... Әмма әсирлектә дә Муса иҗатын дәвам итә. Бу чорда аның балалар өчен дә, зурлар өчен дә язылган «Кызыл ромашка», «Сандугач һәм чишмә» әсәрләре тәмамлана. Шагыйрьнең сагышлы җырларыннан аның фаҗигале юлын тулысынча күз алдына бастырырга була. Җәлил соңгы чиккәчә хәрби антына, Ватанына турылыклы булып кала.

Шагыйрьнең яраланган, ләкин баш бирмәгән лачын йөрәге олы хисләр белән яна. Күренекле патриот-шагыйрь әсирлектә дә балалар әдәбиятының гүзәл үрнәкләрен калдыра.

Әсирлектә чакта шагыйрь, яшерен оешма төзеп, фашистларга каршы пропаганда эшләре җәелдерә. Ләкин бер явыз хыянәтче доносы буенча бу оешманың изге патриотик эше дошманга билгеле була... Фашистлар Мусаны һәм аның иптәшләрен төрмәгә ябалар, үлемгә хөкем итәләр. Җәлилнең соңгы җырлары «палач балтасына башны тоткан килеш» языла.



## БИШЕК ЯНЫНДА

Бәби Гали яткан ак бишеккә.
Яшь әнкәсе аны тирбәтә:

— Әлли-бәлли, бәгърем, бәүки лә,
Йокла, җаным, ятып бишкеңдә.

Ак куллары белән чәп-чәп итә,
Матур җырлар җырлап өйрәтә:

— Әлли-бәлли генә, бәгърем, бәү,
Тыныч кына ятып йоклап ал!..

Тыңлый-тыңлый матур ил җырларын
Тыныч кына йокла, яшь Гали.

— Әлли-бәлли, бәбкәм, бәллүки,
Көйлим икән сиңа нинди көй?!

Йокы аралаш елап көрсенгәли,
Ара-тирә көлеп алгалый.

— Әлли-бәлли, бәбкәм, бәгърем син,
Тыныч йокла, җаным, аргансың.

Йокысында матур төш күрә ул,
Бер кайгыра, бер дә шатлана.

— Әлли-бәлли, бәүки, җанкисәк!
Тыныч йокла тагын бик озак.

Бер елый да тагын көлеп ала,
Бер кычкырып өйгә яу сала.

— Әлли-бәлли, бәүки, ак йөрәк,
Җанкисәгем, тагын ни кирәк?

Кычкырсын да көлсен төшләрендә,
Тик уянып елый күрмәсен.

— Әлли-бәлли, тагын көйләрме,
Йокла шулай, газиз йөрәгем!

Шауламагыз, шайтан, шук балалар,
Ял булганчы Гали йокласын.

— Әлли-бәлли, бәгърем, бәүки лә,
Йокла, җаным, ятып бишкеңә!



## ӘЙДӘГЕЗ, ДУСЛАР!

Әйдәгез, дуслар,
Барыйк өмәгә!
Сыналсын көчләр
Шушы өмәдә.
Алыйк көрәкләр,
Алыйк сәнәкләр.
Бездә бит дәрт бар,
Көч бар, сәләт бар.
Барыйк болынга,
Әйләник кырлар.
Әйбәт урынга
Казыйк чокырлар.
Казыйк чокырлар,
Ул чокырларга
Күмик орлыклар
Шунда кунарга.
Кунарлар алар,
Сеңәрләр алар,
Бераздан өскә
Чыгарлар алар.
Үсәр алардан
Тәмле җимешләр,
Кавын-карбызлар
Һәм көнбагышлар.
Ул бит, беләмсез,
Безнең көч булыр.
Алар, сизәмсез,
Безнең эш булыр.
Без, куанышып,
Бакчага барып,
Кайтырбыз өзеп,
Барын да алып.

Бар дус, туганнар,
Балалар белән,
Күргән-белгәннәр,
Яңалар белән,
Уртак берләшеп,
Көлеп, уйнашып,
Ашарбыз, дуслар,
Кыш буе ташып.
Ул вакыт безгә
Күңелле булыр,
Бик ямьле булыр,
Бик тәмле булыр.
Әйдәгез, дуслар,
Тизрәк өмәгә!
Күренсен эшләр,
Эшлик бу җәйдә!



* * *

Әй абый, син белмисең,
Без уйнадык та соң бүген.
Әй... күңелле булды соң,
Ай-һай... кызык, әйбәт уен.
Барчабыз без — ун бала без,
Җыйналып булдык тәмам.
Су буе булды калабыз,
Чикне куйдык киртәдән.
Шунда, әй... без бервакытны,
Зур чокыр, ярлар ясап,
Суккалап зур йомры тупны,
Уйныйбыз... ай-һай... рәхәт!..
Йөгерәбез, әй... чабышабыз да,
Куышабыз да
Узышабыз.
Тупны куышып алышабыз да,
Сугышабыз да көлешәбез.
Йөгерә-йөгерә без арабыз,
Аркадан тирләр ага...
Кып-кызыл уттай янабыз,
Бар аяк-куллар тала.
Иркәли безне кояш та,
Нур сибә күктән торып,
Ут чәчә ак йөзгә, башка,
Йөз яна уттай булып.

Бервакытны без чабабыз,
Киң инешкә юл алып,
Су коеныргa барабыз,
Тирләгәч, кызгач янып.
Ул инештә, әй, кызык соң,
Әй... рәхәт соң, билләһи!

Ник инеш күк булмаган соң
Елга-күлләрнең бары?!
Аннары соң без тагын да,
Кыңгырау-баулар тагып,
Ат булып, су кырларында
Уйнадык йөгереп-чабып.
Аннан ары кырга чыктык,
Бардык урманга табан,
Андагы, әй!..
Ул матурлык!..
Онытыласың дөньядан!
Җир җиләкләр, андагы ул
Бөрлегәннәр, алмалар —
Бар да тәмле, барсы да мул,
Барсы да баллы алар.
Көн буе йөргәч шулайтеп
Кырда, урманда бүген,
Җырлашып без, шигырь әйтеп,
Калдырып урман юлын —
Туп-туры килдек шушында,
Җәйге мәктәпкә диеп.
Бир китап, абыем, ә, безгә —
Без аны укыйк, күрик.
Уйнап аргач, инде безнең бит
укыйсыбыз килә.
Җимеше бит ул күңлебезнең,
бир китапны, бир генә.
Укыгач, белгәч барын да,
өйгә кайтырбыз да без —
Йоклый-йоклый, бергә-бергә шат узар
һәм төнләбез.

## МАЭМАЙ БЕЛӘН

Әй, Гали уйный энә маэмай белән,
Бик шаян, артык шаян Акбай белән,
Берүзе чабуын тотып чапкан була,
Бер куып, аңар таяк аткан була.
Бер кәләпүшен ала да ыргыта,
Кыздыра, бер эт кебек ыр-ыр итә.
Әмма маэмай да наян, барсын белә,
Нәкъ туган күк тик уенга-көлкегә.
Күп тә узмый, бервакыт кергән Гали,
Шыңшый-шыңшый яшьләнеп зур күзләре.
— Нәрсә булган? Ник елыйсың? Кил, энем!
Нишләдең? Ник әйтмисең? Кайда телең? —
Зарланып, иңрәп, Гали шыңшып кына
Кайтара бик тиз генә җавап миңа:
— Капты да бүрегемне маэмай, ул наян
Менде абзарга, әле төшми һаман!





## КЕЧКЕНӘ ДУСЛАР

Урамда язның җиткәнен күргәч,
Урманда сазның кипкәнен күргәч,
Көрәк алдылар,
Иңгә салдылар,
Кырга бардылар
Кечкенә дуслар!

Кырда җылының үлчәвен белгәч,
Сөргән җиренең тулганын күргәч,
Җирне яхшылап,
Түтәлгә өеп,
Чәчтеләр орлык
Кечкенә дуслар!

Кичкә кадәрле җирне актарып,
Иркен яланда дәртләнеп, янып,
Каршыладылар
Язны эш белән,
Сүнмәс көч белән
Кечкенә дуслар!

## ТУКАЙНЫ САГЫНУ

*(Балалар күңеленнән)*

Арабызда безнең күптән түгел
Яшь агабыз —Тукай бар иде.
Безнең кебек ул да керсез күңел,
Һәр сабыйга якын дус иде.

Уйный иде бергә безнең белән,
Сөя иде безне җан атып.
Ерак иде күңеле тәкәббердән,
Үләр иде безне яратып.

Яза иде безгә җырлар, моңнар,
Әкиятләр, матур шигырьләр.
Өйрәтә иде төрле шәп уеннар,
Туймый иде уйнап күңелләр.

Көлдерә иде безне әкият сөйләп,
Сөендерә иде уеннан,
Моңландыра иде көйләр көйләп,
Күңел ача иде көй белән.

Үлгән инде хәзер ул агабыз,
Аның тәне гүрдә — кабердә.
Аның кайгысына без янабыз,
Бетмәс көенеч безнең бәгырьдә.



# ЛАГЕРЬДА

Җәй буена булдык болында,
Авылларның иркен кырында.
Бергә эшләп, бергә күңел ачтык,
Кайный-кайный басу түрендә.

Таң сигналы белән авылларны
Таңнан торып эшкә уяттык.
Абзыйларга кырда күп басуга
Күчү формаларын өйрәттек.

Эшләп аргач, чумдык инешкә,
Чабак төсле йөзеп шаярдык.
Эшчәнлектә авыл халкы өчен
Үрнәк бала булып саналдык.

Иген керер тиздән амбарга,
Без кайтырбыз таныш калага.
Ишегеңне ач, мәктәп, иркен кырдан
Чыныгып кайткан корыч балаңа.



## МӘЧЕГӘ — КӨЛКЕ, ТЫЧКАНГА — ҮЛЕМ

Бер өер көчек
Фәрит янына
Җыелдылар да,
Төрле ягыннан
Тешләп, капкалап,
Уйнап, тарткалап,
Кайсы өстенә
Менеп, баскалап,
Тик шаярттылар,
Кызык иттеләр.
Фәритнең өстен
Буяп беттеләр.
Фәрит куркудан
Аптырап калды,
Өйне яңратып
Елап җибәрде.
Этләргә көлке —
Тик уйнаталар,
Фәриткә «үлем»,
Фәриткә начар.



## УҢМАГАН ПИОНЕРЛАР

Шакир үзе пионер,
Үзе усал, кыйнаша...
Салютын да бирә белми,
Пионерлар очраса...
Әптерахман да пионер,
Ләкин куркак куян бер,
Кеше белән мәмиләнеп,
Борынын тартып сөйләшә...

Кәрим пычрак, алама...
Кулын буйый карага...
Бертуктаусыз ялана —
Кеше белән сөйләшсә...
Мәхмүт — йокы чүлмәге,
Сасып беткән күлмәге...
«Эш эшләргә барыйк», — дисәң,
Ишек артына кача...
Иха-ха да миха-ха...
Менә кызык ичмаса!..

## ШАКИР БЕЛӘН ГАЛИ

Шакир белән Гали кырдан
Кайтып киләләр иде,
Шакир эчтән бер уй уйлап,
Ашыгып алга йөгерде.

Ул чыкты да басмадан,
Такталарны тарттырып:
— Гали баскач, егылсын, — дип
Куйды чак-чак ләктереп.

Бик аз гына киткән иде,
Очрады бер эт аңа.
Куркып кинәт кычкырды да
Чапты кире басмага.

Куркуыннан онытып,
Басмага килеп керде.
Басма китте ычкынып,
Шакир елгага чумды.

## САНИТАР ҖЫРЛАРЫ

Ягез, дуслар, җыйналыйк,
Мандолин, гармун алыйк.
Санитарның такмакларын
Такмаклап, җырлап алыйк:
Бездә шундый бала бар,
Өсте пычрак, алама...
Итәгенә борынын сөртә,
Иренен буйый карага.
Бездә тагын шундыйлар бар:
Соң ятып, соң торалар,
Йокы белән сасып беткән,
Тынчып беткән булалар.
Аннан соң бар аңгыралар —
Докторлардан качалар,
Авыруларын яшерәләр,
Саулар белән яталар.
Менә мондый тинтәкләргә
Сөйләгез, өйрәтегез,
Тазалыкка, чисталыкка
Күндерегез, әйтегез!

## БАКЧАДА — ӨМӘДӘ!

Карлар эрегәч,
Сулар йөгергәч,
Болын яшәреп,
Ямьләнеп көлгәч,
Без беркөн шулай
Шушы җирләргә
Җыйналып килдек
Язгы өмәгә.
Ул вакыт бу җир
Баткак, саз иде.
Без тизәк җәйдек,
Түтәл казыдык,
Ул түтәлләргә
Орлык утырттык.
Шуннан елгадан
Ташып су сиптек.

Җәй көне алар
Кояш астында,
Көлеп, уйнаклап,
Чәчәк аттылар.
Орлыклар хәлен
Белгән шикелле,
Йомшак болытлар
Яңгыр китерде.
Көз килгәч, алар
Җимеш бирделәр:
Кишер, кәбестә,
Татлы тамырлар.
Без тагын менә —
Эшлекле куллар,
Яшь төзүчеләр,
Яшь пионерлар—

Сигнал бирдек тә
Бергә җыелдык,
Көзге бакчага
Өмәгә килдек.
Йә, өмәчеләр,
Карап тормагыз,
Җирне буйлагыз.
Казыгыз, тырнагыз!
Пешкән җимешнең
Барын да җыйныйк.
Бакчаны язга
Сөреп калдырыйк!







# КӨЗ ҖИТТЕ

Киң болыннарда,
Урман-кырларда
Агачлар, гөлләр,
Күрәмсез,
Кибеп сулдылар.

Уйсу җирләрдә,
Елга, күлләрдә
Көзге салкыннан,
Күрәмсез,
Сулар туңдылар.

Көннәр суынды,
Чишмәләр тынды,
Безне калдырып,
Сизәмсез,
Кошлар да китте.

Кошлар шикелле
Бергә гөр килеп,
Мәктәптә укыр,
Беләмсез,
Вакытлар җитте.



## КҮРСӘТ ӘЛЕ

*(Уенлы җыр)*

— Күрсәт әле, Камали,
Ничек утын яралар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай утын яралар.
— Син әйт әле, Камали,
Кайдан утын алалар?
— Урманнардан, урманнардан
Барып, кисеп алалар.

— Күрсәт әле, Кәримә,
Ничек чаңгы шуалар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай чаңгы шуалар.
— Син әйт әле, Кәримә,
Нигә чаңгы шуалар?
— Чаңгы шуган яшь балалар
Таза, матур булалар.

— Күрсәт әле, Сираҗи,
Ничек мылтык аталар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай мылтык аталар.
— Син әйт әле, Сираҗи,
Кайдан атып яталар?
— Окоп казып, окоп казып,
Шуннан атып яталар.

— Күрсәт әле, Гөлчирә,
Ничек салют бирәләр?

— Менә шулай, менә шулай,
Шулай салют бирәләр.

— Син әйт әле, Гөлчирә,
Кемнәр күпне беләләр?

— Пионерлар, пионерлар,
Шулар күпне беләләр.

## КОШЛАРНЫ КАРШЫ АЛАБЫЗ!

Колхозларның уңышын корткычлардан
Саклый торган җитез чибәрләр,
Тиздән инде канат җилпи-җилпи,
Безнең якка кайтып җитәрләр.

Без оялар, җыйнак кормушкалар
Ясап куйдык, алар кайтыр, дип.
Уңыш өчен бергә көрәшкәнгә,
Алар безгә дус бит, якын бит!..





## КУЯН

*(Уенлы җыр)*

Куян салкыннан
Туңган, куырылган,
Башы салынган,
Колагы шиңгән.
Әйдәгез, дуслар,
Аны терелтик.
Җылы бүлмәгә,
Мәктәпкә илтик.
Куян уянды,
Куркып уйланды,
Сикреп урманга
Чабып югалды.

— Куян, син кайда?
— Яшел тугайда.
— Куян, син кайда?
— Ерак чүлләрдә.
— Куян, син кайда?
— Калын урманда.
— Куян, син кайда?
— Карлы буранда.
— Әйдәгез, дуслар,
Кырны, урманны,
Чүлне актарып
Табыйк куянны.



## КҮҢЕЛЛЕ ЯШЬЛӘР

Йомшак кына җылы җилләр исте,
Тирбәндереп матур инешне!..
Җыйналыгыз, дуслар, уйнап-көлеп,
Ямьләндерик эшле тормышны!..
Илебезне өзелеп сөйгән өчен,
Зур төзелешкә көчне бирдек без,
Эшләп арган тәнгә хәл җыярга,
Ял итәргә монда килдек без.
Гөлчәчәкләр белән кочаклашып,
Иркен сулап таза һаваны,
Уйнап-көлеп кырда күңел ачыйк,
Тәнгә җыйыйк көчне, яңаны!..
Без инештә шаян балык төсле
Башыбыз белән суны сөзәбез,
Ә күз җиткәч, биреп бөтен көчне,
Укуда да оста йөзәрбез.

Йомшак кына җылы җилләр исте,
Тирбәндереп матур инешне...
Җыйналыгыз, дуслар, уйнап-көлеп,
Ямьләндерик эшле тормышны.







## ЭШ ДУСЛАРЫ

*(Идиллия)*

Ир бала:

Әйдә, дустым, урманга,
Күмәкләшеп, гөрләшеп,
Баглар җиткән урманда,
Гөлләр үскән юлларга.
Җир җиләкләр пешкәннәр,
Карлыганнар үскәннәр,
Салкымлашып, уйнашып,
Гөлҗимешләр җиткәннәр.
Әйдә, урман күңелле,
Урман ача күңелне.
Уртаклашып, берләшеп,
Җырлыйк көлке-уенны.
Анда гөлләр аллана,
Тал буйлары ямьләнә.
Чыркылдашып, уйнашып,
Кошлар-кортлар җанлана.

Әйдә, урман сөйкемле,
Урман җыйган иркенне.
        Әйдә, шунда җырлашып,
Уйнап калыйк бу көнне.
Анда кошлар сайраша,
Күгәрченнәр гөрләшә,
        Бергәләшеп, серләшеп,
Күбәләкләр уйнаша.
Әйдә, дустым, урманга,
Бергә-бергә уйнарга,
        Яшьлек үткәч, уйлашып,
Калсын сагынып сөйләргә.
Әйдә, бергә уйнарбыз,
Җир җиләген җыйнарбыз,
        Моңланышып, көйләшеп,
Ил җырларын җырларбыз.

К ы з   б а л а:

Ай-һай, дустым, ярамый,
Торып торсын алары,
        Безне көтә моңланып,
Еракта эш яланы.
Анда иркен, күңелле,
Ташла, дустым, уенны.
        Әйдә, бергә чынланып,
Бизик ямьле болынны.
Анда хезмәт, анда эш,
Анда кырык төрле төс.
        Башка дуслар сызганып
Түгәләр мең төрле көч.



Бит ашлыклар үскәннәр,
Башаклары пешкәннәр,
Безнең кебек балалар
Күптән барып җиткәннәр.
Кил, сүземне аңласаң,
Ялкаулыкка калмасаң,
Эштән качып калырга,
Дусыңнан оялмасаң.
Билбавыңны так билгә,
Урагыңны ал кулга,
Ак кулларны сызганыйк та
Китик иркен болынга.
Иркен кырга барырбыз,
Кулны эшкә салырбыз,
Күгәрчендәй гөрләшеп,
Урак урып алырбыз.
Бездә бөек яшь йөрәк,
Бездә таза ак беләк,
Эш вакытында, иренмичә,
Эшләп калырга кирәк.

И р  б а л а:

Дустым, дөрес әйтәсең,
Бетте сүзем-әйтәсем,
Әйдә китик бергәләп,
Эш болыны кайда соң?!
Бир кулыңны, ант итик,
Ямьле бәйрәмгә китик,
Эш көнендә тирләп-пешеп
Эшлик тә бәйрәм итик.

Бергәләшеп:

Без ирекнең дуслары,
Ак бәхетнең кошлары,
Иркен көндә кырда эшләп
Ямьләтәбез дөньяны.
Әйдә кырга — эшләргә,
Ак ярдәмгә дусларга.
Эшләп аргач, соңыннан,
Өлгерербез уйнарга.
Өлгерербез, арырбыз —
Киң урманга барырбыз,
Бергәләшеп, җырлашып,
Уйнап-гөрләп калырбыз.







## ЧАҢГЫ ЭЗЕ

Яшь балалар чаңгы шуа
ала карда,
Агач башына килеп кунды
кара карга.
Карга белән тик без икәү
эшсез монда,
Шумыйбыз да, тик торабыз
сүзсез генә.
Карга карый, мин дә карыйм,
нинди кызык!
Чаңгы үтә тигез, матур
сызык сызып.

Миңа бу кар язылмаган
кәгазь төсле.
Чаңгы эзе —
аңар язу
язган төсле.
Әнә Равил чаңгы белән
рәсем төшерә.
Менә Камил немецча бер
шигырь күчерә.
Әнә Марат пионерлар
антын яза.
«Ике сигез — уналты» дип
язган Роза.
Чаңгы эзен мин үземчә
укыйм, төшенәм.
Бу эзләрдә гәүдәләнгән
яңа кешеләр.
Бу эзләрдә галстуклы
яшь буынның
Чикләнмәгән дәрте, алга
ашкынуы.
Монда — күмәк тормыш белән
туган шатлык.
Сыйнфый дуска — дуслык,
дошманга —
дошманлык.
Йөрәгемә тирән сеңгән
бу тойгылар.
Мин аларны рәхәтләнеп
укыйм шуңар.

Ә менә бу кара карга
нәрсә карый?
Карап тагын нәрсә аңлый,
нәрсә таный?

Шул уемны сизгән кебек
кара карга:
— Кар-р! — диде дә очып китте
ала тауга.
Шулай итеп, яр башында
ялгыз калдым,
Чаңгы эзен шул кәгазьгә
күчереп алдым.

## КҮКЕ

Калын урманда
Гел кичкә каршы
Ишетелә моңлы
Бер кошның тавышы:
— Кәккүк, кәккүк,
Кәккүк, кәккүк!

Ул салмак кына
Кабатлый шуны,
Шул аның җыры,
Шул аның моңы:
— Кәккүк, кәккүк,
Кәккүк, кәккүк!

Ул ялгыз яши,
Чыгармый бала,
Менә шунлыктан
Ямансу аңа!
— Кәккүк, кәккүк,
Кәккүк, кәккүк!



# ЧИШМӘ

Яр астыннан чишмә ага,
Челтер-челтер тавышы.
Җил искәндә иелеп кала
Читкә үскән камышы.

Челтер-челтер чишмәбез,
Ярдан балчык ишмәгез!
Суны шуннан эчегез,
Башка җирдән эчмәгез!

Пионерлар чишмәсеннән
Колхозчылар су ала.
Кызыл сакчы аргамагын
Шул чишмәдән сугара.

Челтер-челтер чишмәбез
Күгелҗем тау ярында.
Су эчмичә китмәгез,
Поход үткән чагында!





## ӘТӘЧ

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!
Йә сузып кына,
Йә бик еш кына:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Аңа кушыла
Башка әтәчләр:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!
Картлар артыннан
Шаулаша яшьләр:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!
Бакчага килдек,
Ашыга-ашыга:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

# ШМИДТ БАБАЙ

Боз диңгезендә,
Бозларны ватып,
Шмидт бабай яңа юл сала.
Ул курыкмый бер дә,
Буран уйнатып,
Бозлы яңгыр явып торса да.

Ул кичә генә
Төньяк диңгездән
Кайтты тагын безнең көньякка.
Һәм бүләк итеп
Бу юлы безгә
Ап-ак тере аю алып кайткан.

Аю үкерә,
Балалар көлә —
Аның тавышы безне куркытмый.
Ә Шмидт бабай
Иркәли безне,
Зур сакалы битне кытыклый.



# МАЭМАЙ

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә.

Хәзер аңа мин сугыш
Һөнәрләрен өйрәтәм.
Чаптырам да сикертәм,
Көн дә шулай йөдәтәм.

Ул окоптан окопка
Хат ташырга өйрәнсен!
Командирын дошманнан
Яклашырга өйрәнсен!

Яралыга су илтсен,
Һәрнәрсәгә өлгерсен.
Нәрсә генә сизсә дә,
Командирга белдерсен.

Менә шуның барсын да
Мин өйрәтәм Акбайга.
Акбай әзер һәрвакыт
Туган илен сакларга!



## БЕРЕНЧЕ ДӘРЕС

Без бу ел гына
Мәктәпкә килдек.
Аңарчы һаман
Бакчада идек.

Мәктәп өр-яңа,
Анда парталар,
Алар күңелне
Эчкә тарталар.

Кулыбызда безнең
Яңа Әлифба.
Менә монсы «а»,
Менә монсы «ба».

Без хәрефләрдән
Сүзләр ясыйбыз,
Шуннан соң җырлап
Укый башлыйбыз:

Ат,
ата,
арта,

Ат арба тарта.
Ата-аналар
Атта баралар.

Нинди зур бәхет,
Нинди үзгәреш!
Бигрәк күңелле
Беренче дәрес!





# КАРАК ПЕСИ

### 1

Чоландагы ак майга
Иялəшкəн күселəр,
Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигə:
— Мияу, мияу, пескəем!
Барчы, зинһар, чоланга,
Майны сакла күседəн,
Оясыннан чыгарма!

### 2

Песи күргəч, күселəр
Койрыкларын кыстылар.
Йөрмəделəр чабышып,
Ярыкларга постылар.
— Мияу, мияу, пескəем!
Колак салдың сүземə!
Каравылдан бушагач,
Сөт бирермен үзеңə!

### 3

Иртə белəн майга дип
Керсəм, күзем акайды:
Явыз песи берүзе
Ялт иттергəн ак майны!
— Мияу, мияу, пескəем,
Хыянəтче икəнсең,
Саклый торган маеңны
Үзең ашап беткəнсең!

# СӘГАТЬ

Сәгать суга: «Даң-даң!..»
Хәбәр бирә таңнан:
— Бакчага барырга
Унбиш минут калган.

Сикереп торды Марат,
Күрә — эшләр харап.
Тагын соңга калган,
Шул йокыга карап.

Сәгать йөри: «Келт-келт!..»
— Тиз бакчага кит, кит!..
Марат аңа дәшә:
— Тукта, мине көт, көт!..

Сәгать җырлый: «Диң-диң!..»
— Мин бит туктый белмим.
Моннан ары «зиң-зиң!»
Миңа карап йөр син!..



## БИШЕК ҖЫРЫ

### 1

Күз нурым син,
Матурым син,
Тулган аем!
Ай туганда
Йокла инде,
Матуркаем!
Такмак әйтер
Сиңа җилләр,
Алмагачы әкият сөйләр.
Йокла, нәни,
Йокла, бәби,
Әлли-бәлли,
Бәлли-бәү!

### 2

Син үсәсең,
Матурланып,
Алсу гөлдәй.
Гөлләр үскән
Иң бәхетле
Матур илдә.
Гөлләр сине
Назлап сөяр,
Кояш, көлеп,
Башын ияр.
Йокла, нәни,
Йокла, бәби,
Әлли-бәлли,
Бәлли-бәү!

# УЕН

Эшләгәчтен, аргачтын, яшь беләкләр талгачтын,
Йомшак тәннәр оешып, эшләп каннар саугачтын,
Ягез инде уйнарга, иркен һава суларга,
Йөгерешеп, узышып, шаулашырга, гөрләргә!
Киң урманга барырбыз, анда рәхәт алырбыз,
Сикерешеп, куышып, чулап, дулап калырбыз.
Тезелешербез, уйнарбыз, су буйларын буйларбыз,
Кычкырышып, көлешеп, көйләрбез дә җырларбыз.

Менә шунда ямь безгә, ләззәт безгә, тәм безгә,
Мәңге яшә син, уен! Бәйрәм синдә, җан синдә.





## БЕР ШИГЫРЬ

Без эти белән икәү
Охшаганбыз төс белә:
Борныбыз да кәкере,
Авызыбыз да кечкенә.
Әти мине ярата,
Бик кадерләп үстерә,
Мин йөткерсәм — йөткерә,
Мин төчкерсәм — төчкерә.
Әти миңа охшаган,
Мин әтигә охшаган:
Әти миңа ышана,
Мин әтигә ышанам.
Алма алмагачыннан
Ерак төшми, диләр бит!
Алтын була кечкенә,
Артык үсми, диләр бит!

*Сәлам белән Чулпан*

## КЫЗЫМА

*(Бишек җыры)*

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем.

Синең гомрең җыр булып
Янар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып бакчада
Син уйнадың көнозын.
Аргансыңдыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым!

Әлли-бәлли, бәлли-бәү!
Әлли-бәлли, бәлли-бәү!



## ПАРАШЮТСЫЗ КУРЧАК

Әти миңа куык алып бирде,
Мин курчагым тактым аңарга.
Очып китте куык,
                                        аның белән
Курчагым да очты һавага.

Мескен курчак!
Әгәр парашюты
Булган булса иде янында,
Парашюты белән сикереп кенә
Төшкән булыр иде алдыма.

Әти тагын куык алып бирсә,
Мин курчакны таксам куыкка,
Аркасына аның парашютын
Бәйләп җибәрергә онытмам.



## СЕБЕРКЕ ӘКИЯТЕ

Борын-борын заман
Булган, ди, бер бабай,
Өч баласы булган,
Өчесе дә малай.

Тик үзара алар
Тату тормаганнар,
Берсен-берсе һаман
Суккан, хурлаганнар.

Үләр көне җиткәч,
Балаларны бабай
Үз янына дәшкән.

Өчесенә, бәйләп,
Өч себерке биргән:
— Таратмыйча шуны
Сындырыгыз,— дигән.

Ә малайлар һич тә
Булдыралмаганнар,
Тоташ себеркене
Сындыралмаганнар.

Шуннан бабай бер зур
Себеркене чишкән.
Һәр чыбыкны аерым
Сындырырга кушкан.

Ә малайлар моны
Шундук булдырганнар.
Һәр чыбыкны аерым
Җиңел сындырганнар.

Бабай әйткән:
— Шулай
Аерым яшәсәгез,
Һич оешмасагыз
Һәм берләшмәсәгез —
Дошман сезне җиңел
Сындырыр да ташлар.
Үрнәк алыгыз менә
Себеркедән, яшьләр!

## КУЫК

Илдар чыкты урамга,
Куык белән уйнарга.
Очып китте куыгы,
Ул каранып торганда.
Җилләр килеп җиттеләр,
Алай-болай иттеләр
Һәм куыкны һавага
Алып менеп киттеләр.
Күрәсеңме куыкны,
Үтеп китте кыекны!
Шуны күргәч, Илдарның
Кинәт күңеле боекты.
Еларга да белми ул,
Көләргә дә белми ул,

Күзен алмый куыктан,
Нишләргә дә белми ул.
Менә халык җыйналды,
Тулып китте йорт алды,
Кайсы карый югары,
Кайсы назлый Илдарны.
Куык оча бик җитез,
Күтәрелә шундый тиз!..
Менгән саен кечрәя,
Чак аера инде күз.
Бар да карый куыкка,
Күңелле дә, кызык та!
— Карагыз,— дип,— карагыз,
Хәзер җитә болытка!..
Илдар тора аптырап,
Иреннәре калтырап.
Килеп басты янына
Бер очучы лейтенант.
Шуны күргәч, Илдарның
Йөзе кинәт ачылды
Һәм, шатланып, ул аның
Җиңенә килеп асылынды:
— Абый, син бит очучы!
Самолетка утырчы!
Күктән минем куыкны,
Табып, җиргә төшерче!
Самолетта син аны
Бик тиз куып җитәрсең,
Куып җиткәч куыкны,
Миңа хәбәр итәрсең.
Минем куык болытка
Барып кергәндер инде.
Су үтмәсен куыкка,

Абый, тизрәк бул инде!..
Көлештеләр барсы да,
Очучы да елмайды,
Утыртты да алдына,
Кочаклады Илдарны:
— Очуын мин очармын,
Очу ул бик кызыклы!
Ләкин мин бит танымам
Күктә синең куыкны.
Тиздән үзең үсәрсең,
Өйрәнерсең очарга.
Һәм менәрсең һавага
Куыгыңны тотарга.
Үзең аны тиз танып,
Очып куып җитәрсең,
Самолетыңа тагып,
Җиргә алып төшәрсең.
Илдарга бу ошады,
Чын күңелдән шатланып:
— Ярый, — диде, — алайса,
Үскәч, үзем очармын.
Өйрәнермен очарга
Һәм табармын куыкны.—
Ул очучы булырга
Уен шулай ныгытты.
Илдар кич тә, көндез дә
Күккә карый моңаеп.
Уйлый, аның куыгы
Һаман шунда тора дип.
Ул очучы булырга
Көн дә антын яңарта.
Белемгә һәм эшкә дәрт

Үсә көн дә аңарда.
Еллар үтәр, билгеле,
Куыгы аның онтылыр.
Тик онтылмас очуга,
Яңалыкка омтылу.
Илдар үсәр һәм булыр
Илнең батыр кешесе,
Иң җитез һәм иң биек,
Иң ерак очучысы.
Табалмаса табалмас
Юкка чыккан куыгын,
Ләкин үскәч, ул табар
Күккә очу кызыгын.
Табар җиңү шатлыгын,
Табар үсү тойгысын.
Биеклеккә омтылу —
Бизәр аның тормышын!



4*

# ҖИЛЛӘР

Җилләр, җилләр, исегез,
Болытларны кисегез!
Зәңгәр диңгез өстендә
Ак дулкыннар ишегез!

Алтын бодай кырларын
Тибрәндереп үтегез!
Боз тауларын куарга
Төньякларга китегез!

Җилләр, җилләр, сез җитез,
Сез исәсез нинди тиз!
Тик бер сорау бирергә,
Зинһар, рөхсәт итегез!

Җир йөзендә шундый тук,
Шундый иркен тормышлы,
Шундый киң һәм шундый нык,
Шундый матур күренешле,
Әллә ничә диңгезле,
Әллә ничә урманлы,
Шат кояшлы, көндезле
Тагын берәр ил бармы?

Җилләр, җилләр әйттеләр:
— Мондый ил тик бер генә;
Чәчәк кенә, гөл генә
Безнең туган ил генә.



# УРМАН

Бала чакта бергә җиләк җыйган
Урман буйлап үтә юлыбыз.
Без китәбез инде, дус каеннар,
Йә, хәзергә хуш-сау булыгыз!

Үкенечкә, шаять, калмагандыр,
Күп буйладык, урман, буеңны!
Нарат башларына үрмәләдек,
Имән төпләренә сыендык.

Талдан талга күчеп куышып йөрдек,
Ботакларга басып тирбәндек,
Күпме уен, күпме җыр өйрәндек,
Бар да, бар да сагынып сөйләрлек.

Урман безне юаш ана төсле
Иркәләде:
Кызу көннәрдә —
Күләгәләп торды өстебездән,
Ышыклады яңгыр килгәндә.

Җыр җырласак, дәртле җырларыбыз
Кабатланды аның теләндә.
Яшеллегең,
Яшьлек җырың белән
Сакланырсың, урман, күңелдә!..
Канат чыккан үсмер кошлар төсле
Без очабыз инде еракка,
Акыл үсте.
Хәзер тар ояда
Тик ятуы ят та, оят та.

Без укыйсы фәннәр,
Без эшлисе
Данлы эшләр безне көтәләр.
Ахры, дәртләр безне, канат булып,
Башкалага алып китәрләр.

Бала чакта бергә җиләк җыйган
Урман буйлап үтә юлыбыз;
Без китәбез инде, дус каеннар,
Йә, хәзергә хуш-сау булыгыз!

Җылы якка очырып кошчыкларын,
Ялгыз калган төсле,
Моңаеп,
Артта калды урман.
Һәр аерылу
Читен була микән шулай ук?!

Моңайма син, урман!..
Гаҗәпмени
Аерылуы синнән кошыңның?!
Үз гомереңдә азмы бала кошны
Канат биреп шулай очырдың?!
Моңайма син,
Синең горур даның
Һәм син кичкән җилләр, давыллар
Син очырган дәртле кошларыңның
Җырларында ерак яңгырар!





## КЫЗЫЛ РОМАШКА

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

Назлады җил аларны,
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр.
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.

Ерак түгел моңаеп
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Ромашкалар бар да ак,
Аерылмый бер-береннән;
Ничек болай берүзе
Ул кызылдан киенгән?

Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нигә кызыл чукларың?
Нидән алсу төсләрең?»



Әйтте кызыл ромашка:
«Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.

Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы.
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.

Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып
Балкыйм мин таң нурында».





## САНДУГАЧ ҺӘМ ЧИШМӘ

*(Баллада)*

**1**

Таң атып, нурлары
Үпкәндә кырларны,
Чишмәләр, күлләрне
Һәм калын урманны,

Сандугач, уянып,
Канатын кагына
Һәм карый ашкынып
Тын урман ягына.

Ул якын сердәше
Чишмәне сагына;
Таң кошын юксынып
Чишмә дә зарыга.

Сихерле тормышы
Бу ике гашыйкның
Кабынды мәхәббәт
Утында яшьлекнең.

Бәйләде аларны
Ялкынлы саф сөю;
Саф сөю алдында
Нечкәреп баш ию.

Һәр иртә Сандугач
Чишмәдә коена.
Бу аңа чиксез зур
Дан булып тоела.

Иркәли таң кошын
Зөбәрҗәт тамчылар.
Әйтче, бу күрнешкә
Сокланмый кем чыдар?!

## 2

Таңнарның берендә
Иркә кош — Сандугач,
Уянып карангач
Һәм канат кагынгач,

Килде тиз сердәше
Чишмәгә...
Тик аның
Кайгылы моң баскан
Чәчәкле буйларын.

Чишмә тын; ул көлми,
Тибрәнми, селкенми;
Акбүз таш өстендә
Тамчылар сикерми.

Болганып каралган
Көмештәй саф суы;
Уйлары таралган,
Йөрәге ярсулы.

Сандугач аптырап
Сорашты дусыннан.
Һәм әйтте сердәше
Дип: «Кичә шушыннан

Үтте ил дошманы,
Яшеренеп, яр буйлап,
Минем саф, шифалы
Суымны агулап.

Канечкеч, юлбасар,
Ул кача артыннан
Аны нык күзәтеп
Килгән яшь батырдан.

Ул белә батырның
Инешне кичәсен
Һәм, сусап, минем саф
Суымны эчәсен.

Ул эчкәч, агудан
Шул минут үләчәк.
Ә дошман, котылып,
Талап көн күрәчәк.

Әйт, нишлик, сердәшем?
Әйт, нишлик, акыллым?
Ничек соң коткарыйк
Илебез батырын?»

Сандугач аз гына
Уйланып торды да
Җанланып эндәште
Чишмәгә тын гына:

«Кайгырма, күз нурым!
Ул килсә эчәргә,
Коткарам мин үзем,
Мин беләм нишләргә!»

### 3

Килде ил батыры
Мылтыктан, кылычтан,
Йөрәге һәм анты
Катырак корычтан.

Илгә саф мәхәббәт
Ярсыта йөрәген,
Дошманны юк итү
Аның бар теләге...

Ул арган, алҗыган
Татып яшь ачысын,
Ах, әгәр булсачы
Бер генә тамчы су!

Ул күрде Чишмәне,
Төште тиз атыннан,
Әлсерәп үзәген
Көйдергән ялкыннан.

Ул теләп эчәргә
Чишмәгә омтылды.
Шул вакыт Сандугач
Сайрарга тотынды.

Ул сайрый Егетнең
Алдына ук кунып,
Ул сайрый, нәрсәдер
Сөйләгәндәй булып.

Ул сайрый ялкынлы
Саф сөю турында
Һәм сөйгән йөрәкнең
Ярсуы турында.

Ул мактый көрәштә
Кабынган тормышны,
Дан белән суланган
Иң соңгы сулышны.

Ул мактый дустына
Бирелгән күңелне,
Ул сөйли сөюнең
Җиңгәнен үлемне.

Ул сөйли чын дуслык,
Турылык турында,
Нинди көч бу кошның
Ялкынлы җырында!

Тик Егет аңламый
Телен таң кошының,
Тойса да йөрәге
Хисләрен дусының;

Серле җыр иң нечкә
Кылларын күңелнең
Чиртсә дә, ул сизми
Килгәнен үлемнең.

4

Эчәргә дип Егет
Чокырга иелә,
Һәм кипкән иренен
Чишмәгә тидерә.

Шул вакыт кош аның
Иренендә сугыла,
Бер тамчы эчә дә
Чишмәгә егыла.

Сөйгәне куенында
Соңгы кат талпынгач,
Шат, мәгърур һәм батыр
Җан бирә Сандугач.

Ә Чишмә, чайкалып,
Ярларга ташлана.
Урнында тик көйгән
Кап-кара таш кала.

Яшь Егет аз гына
Торды да инештә,
Таң калып бу серле
Һәм гали күрнешкә,

Чишмәне калдырып,
Атына атланды.
Юлбарыс шикелле,
Дошманга ташланды.

Ул сизде күңлендә
Иң гали хисләрнең
Өр-яңа көч белән
Кабарып үскәнен.

Ул улы хөр илнең
Һәм бөек атаның,
Ялкынлы йөрәктән
Ул сөя Ватанын.

Яшәде ул сөеп,
Һәм үләр бер көнне
Нәкъ мәгърур Сандугач
Һәм Чишмә шикелле.



# ИМӘН

Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра бер карт имән.
Тирә-ягы яшел чирәм,
Ботаклары җиргә тигән.

Таң җилләре җилфер-җилфер
Җилфердәтә яфракларын.
Имән җырлый, искә төшереп,
Шаулап үткән яшь чакларын.

Мең ел элек кемдер монда
Җир казыган, тир тамызган.
Һәм беренче кат имәннең
Яшәү иртәсен кабызган.

Кем дә белми ул кешене,
Игенчеме, бакчачымы,
Яшеллек һәм хәят сөйгән
Батыр хезмәт патшасымы?

Кем булса да, туфрагында
Җир саклаган аның тирен.
Һәм карт имән гомре белән
Бүләкләгән бу эш ирен.

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы — моңлы җырчы —
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшрен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.
Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңә
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә, эше калсын
Мең яшәрлек имән булып.



## СЕРЛЕ ЙОМГАК

Әкияттәге серле йомгак булып
Тәгәрәде тормыш сукмагым,
Озак бардым, ахры, көн батканда,
Шушы йортка арып туктадым.

Әкияттәге дию патшасыдай,
Йорт хуҗасы чыкты каршыма.
Балта аскан, бөркет үләксәсен
Бүрек итеп кигән башына.

Әкияттәге төсле тимер капка,
Күз кадәрле тишек капкада.
Дию карап һәр көн шул тишектән
Корбаннарын санап мактана.

Дию өчен көн дә йөз учакта
Кәбаб кыза адәм итеннән.
Шушы йортта икән кара бәхтем,
Мине илдән тартып китергән.

Эх, сез, шомлы әбием әкиятләре,
Кая сезгә җиту чынлыкны?!
Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга
Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны!

Кая гына аяк атласаң да,
Саклый монда дию тозагы.
Һәр тыкрыкта үлем күләгәсе,
Һәр ишектә коллык йозагы.

Шундый тәртип монда: акылы барның
Балта белән башын чабалар.
Ишекләре бикле килеш яна
Карт аналар, бала-чагалар.

Дию өчен зифа билен бөккән,
Мәхрүм булып аштан, иректән,
Илләреннән куып китерелгән
Хөрмә кебек кызлар, егетләр.

Йөрәк елый, таныш яңакларда
Канлы яшь һәм сулган төс күреп.
Күргәннәрем шомлы әкият кебек,
Кичергәнем авыр төш кебек.

Нәүбәт җитәр миңа, тик мин үлгәч,
Җырларымны минем кабатлар
Мин юлымда туктап назлап үткән
Гөлҗимешләр, гөлләр, наратлар.

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.



# ТИЛГӘН

*(Бәбкә саклагандагы балалар такмагы)*

Көш-көш, тилгән,
Йөрмә гел түбән,
Үрдәк алудан
Өмет өз, тилгән!
Түбән очасың,
Бәбкә кочасың,
Очып кач моннан,
Ашыгып, тиз, тилгән!



Суларда йөрсәң,
Бәбкәгә тимә!
Кырларда йөрсәң,
Чебешкә тимә!
Без — бар сакчылар —
Дошманбыз сиңа,
Йөрсәң бу җирдән,
Үлем сиз, тилгән!







# ДЖИМ

*(Поэма)*

Фашистик Германиядә 1935 елда чыгарылган декрет буенча ариецларның балаларына, ягъни немец балаларына, кара тәнлеләрне сурәтләгән курчаклар белән уйнау кискен рәвештә тыела.

*(Газеталардан)*

Зәңгәр күзле уйчан Эммага
Алты яшь тулды.
Һәм әтисе кичен кунаклар
Җыярга булды.
Эмма көтә: тиздән әтисе
Заводтан кайтыр.
Кочагына алып кызчыгын
Назлар, юатыр.
Аның белән бергә кайтырлар
Кунак абзыйлар
Һәм Эмманың нәни күңелендә
Шатлык кабызырлар.
Эмма өчен бүген көтмәгән
Зур бәйрәм булыр.
Бәлки, бүген аның ачлыгы да...
Бар да онтылыр.

Сез белмисез нәни Эмманы —
Ул нәфис чәчәк,
Ләкин һава һәм су юклыктан
Иртә шиңәчәк.
Ул дөньяда балкып, кинәнеп
Яшәргә тели.
Ул болытлар белән ярышып
Яшьнәргә тели.
Сезнең төсле ул да ярата

Туклыклы ашны.
Ул да сөя назлы карашны,
Якты кояшны.
Бит аның да матур киемнәр
Киясе килә.
Кояш нурларында коенып,
Көләсе килә.
Ләкин әле алар яшәгән
Илнең күгендә
Кара байрак уйный, төренеп
Кара сөремгә.
Әле анда явыз фашистлар
Хуҗа барсына.
Анда җәйгән кара канатын
Фашист-карчыга.
Ул батырган халык тәненә
Канлы тырнагын.
Ул көйдергән немец иленең
Якты кырларын.

Ул Эмманы япкан караңгы,
Салкын подвалга;
Ирек бирми аңа елмаеп
Тышка карарга.
Ул урлаган аңа тиешле
Якты кояшны,
Саф һаваны, суны, ирекне
Һәм тәмле ашны.
Эмма килә кайчак тәрәзгә,
Зарыгып, интегеп.
Ләкин анда күрә ул бары
Фашист итеген.
Анда йөри калын бер шупо[1],

[1] Шупо — фашистик Германиядәге полицейский.



Йортны караулый.
Подвал эче шундый күңелсез,
Шундый караңгы.
Эмма ябык, Эмма кечкенә;
Киеме дә юк.
Шуңа күрә чыкмый урамга,
Утыра боегып.
Әтисе аның таңнан китә дә
Соң гына кайта.
Ул кайтканчы Эмма, чишенеп,
Йокларга ята.
Әнисе юк нәни Эмманың,
Өйдә беркемсез,
Авырып ята сукыр әбисе,
Нинди күңелсез!

## 2

Бүген булыр аның бердәнбер
Шатлыклы көне.
Ул шаярыр, бөтен кайгысы
Беткән шикелле.
Әнә кайтты аның әтисе,
Көлә еректан.
Аның белән бергә килгәннәр
Эшче кунаклар.
Алар бар да юаш, акыллы,
Бар да сөйкемле.
Ул көн Эмма һаман шаярды,
Һаман сикерде.
Кунакларның берсе, тәбрикләп,
Нәни Эммага
Бүләк итте курчак, курчагы —
Бер негр малай.
Эмма аны чиксез яратты:
«Чын дустым», — диде.



«Исеме аның, әти, ишетегез!
Джим булсын!» — диде.
Ак йөзендә балкый Эмманың
Алсу яктылык.
Күзләренә чыккан бүгенге
Сабый шатлыгы.
Ул кулыннан бер дә төшерми
Кара курчакны.
Яңа дустын әле күтәрә,
Әле кочаклый.
Ул төн Эмма озак уйнады
Кара Джим белән.
Ә кунаклар план сыздылар,
Яшертен генә.
Алар шунда бәхет һәм ирек
Өчен көрәшне
Ничек көчәйтергә кирәген

Бергә киңәште.
Ул көн тышта ап-ак кар яуды,
Буран ыжгырды.
Әллә кайсы тәрәз төбендә
Ачы сызгырды.
Әтисе һәм кунак абзыйлар
Чыгып качтылар.
Эмма гына елап кычкырды
Алар артыннан.
Кире кайтып, аны әтисе
Кочаклап үпте.
— Хәзер кайтам,— диде, үзе, борылып,
Яшьләрен сөртте.

## 3

Ул төн тышта буран үкерде,
Җилләр улады.
Эмма, мескен, Джимны кочаклап,
Үксеп елады.
Шушы төнне аның әтисен
Тотып яптылар.
Икенче көн ике кылычлы
Ишек кактылар.

Сукыр эби авыру, ыңгыраша,
Эмма почмакта
Елап утыра, дер-дер калтырап,
Джимны кочаклап.

Кылычлылар, өйне актарып,
Тентеп бетергәч,
Бернәрсә дә тапмый, ачудан
Сүгенеп төкергәч,
Почмактагы нәни Эммага
Күз төшерделәр

Һәм кулында аның кап-кара
Курчак күрделәр.

Зур мыеклы шунда:
— Җинаять!
Карагыз! —диде.—
Негр белән уйный баласы,
Ах, явыз! — диде.

— Кара тәнле курчак тыела
Ариецларга!
Приказ бирәм: тартып алырга
Һәм сургычларга!
Эмма, мескен, Джимны кочаклап,
Елап кычкырды.
Кылычлыдан куркып, почмакка
Барып утырды.
— Бирмим, бирмим матур Джимымны,
Бирмим, килмәгез!..
Миңа аны бүләк иттеләр,
Зинһар, тимәгез!..

Кылычлылар аның кулларын
Каерып тоттылар.
Таш курчакны тартып алдылар
Һәм ыргыттылар.
Зур мыеклы нидер дәфтәргә
Сызгалап алды.
Матур Джимны, бөкләп, сындырып,
Капчыкка салды.

**4**

Кылычлылар китте. Урамда
Буран үкерә.
Ябылмыйча калган ишектән

Суык җил керә.
Эмма туңа. Аның ачлыктан
Күкрәге чатный.
Берәүсе дә икмәк китерми,
Өйгә дә якмый.

Эмма елый үксеп, яшьләрен
Җиңенә сөртә.
Тәрәзәдән карый, боегып,
Әтисен көтә.
— Ник кайтмыйсың,
            әтием, кайт инде,
Ашыйсым килә...
Әтием-бәгырем,
            кисеп бир миңа
Бер телем генә.



Бик туңам бит, әтием, куеныңда
Җылытса идең...
Куркам, әтием, шул мыеклыны
Син куса идең!..
Әтием, нигә негр курчакны
Алай иттеләр?
Нигә миннән сөйгән Джимны
Алып киттеләр?!
Әтием, тагын кунак абзыйлар
Килерләр микән?!
Миңа тагын берәр Джим алып
Бирерләр микән?!

Эмма туңа, ачыга.
Көн үтә,
Озын төн җитә.
Эмма, мескен, һаман, зарыгып,
Әтисен көтә.
Ә әтисе кайтмый. Бәлки, ул
Кайтмас гомергә.
Эмма ялгыз, әтисе дә юк,
Сөйгән Джимы да...

# ЭЧТӘЛЕК


**Үлемсез җыр** (*Кереш сүз*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Бишек янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Әйдәгез, дуслар! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
«Әй абый, син белмисең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Маэмай белән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Кечкенә дуслар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Тукайны сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Лагерьда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Мәчегә — көлке, тычканга — үлем . . . . . . . . . . . . . . . 18
Уңмаган пионерлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Шакир белән Гали . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Санитар җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бакчада — өмәдә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Көз җитте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Күрсәт әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Кошларны каршы алабыз! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Куян (*Уенлы җыр*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Күңелле яшьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Эш дуслары (*Идиллия*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Чаңгы эзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Күке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Әтәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Шмидт бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Маэмай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Беренче дәрес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Карак песи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Сәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Бишек җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

Уен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Бер шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Кызыма (*Бишек җыры*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Парашютсыз курчак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Себерке әкияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Куык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Җилләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кызыл ромашка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Сандугач һәм чишмә (*Баллада*) . . . . . . . . . . . . . . . 58
Имән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Серле йомгак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Тилгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Джим (*Поэма*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69



Издание для детей и юношества

*Муса Джалиль*

**КУКЛА БЕЗ ПАРАШЮТА**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.М.Касыймова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 05.08.2004. Форматы $70\times100^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы Шартлы буяу-оттиск Нәшер-хисап табагы
Тиражы 5000 экз. Заказ Э–536.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.